ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур.,16 нчы йорт, Килди авылы,
422586

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

10.12.2019 — 42

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

с. Кильдеево

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 декабрендәге 1103 номерлы карары нигезендә яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Урнаштырырга:

2019 елның 20 декабреннән 2020 елның 8 гыйнварына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим;

2. Килди авыл җирлеге халкы тарафыннан пиротехника әйберләрен махсус куллану урыннарын билгеләргә:

Килди авылы
- буа районы;
- соңгы йорттан 500 метрдан да ким булмаган иске лагерь районы.

Уланово авылы
- клуб бинасыннан 500 метрдан да ким булмаган иске ферма территориясе .

Харино авылы
- кырый йорттан 500 метрдан да ким булмаган суэтем башнясы районы.

3. Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәре вакытында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, социаль әһәмиятле объектларны саклауны көчәйтү буенча җаваплы зат итеп Бурдин Виктор Михайловичны билгеләргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Килди авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы — В. М. Бурдин